ГЛАВА КАЗАКЛАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422720, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Казаклар, ул. Советская, 5

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЗАКЛАР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
422720, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Казаклар авылы, Совет ур.,5

Тел./факс: +7(84365) 634-30, e-mail: Kazak.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **КАРАР**

**29 октября 2024 г.** — **№ 7**

**Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлегенең Казаклар, Өлә һәм Наратлык авылларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм көләну мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районының Казаклар авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

Карар кылды:

1. Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлегенең Казаклар авылында үзара салым акчаларын көләну мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 14.11.2024 көненә билгеләргә. Үткәрү вакыты - 11 сәгать 00 минутта. Үткәрү урыны: Казаклар мәдәният йортында адресы: уля авылы, Совет ур., 11 й.

1.1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлегенең Казаклар авылы торак пункты территориясендә даими яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы Сез, свода катнашучы халыктан һәм аларның бергә яшәүче гаилә әгъзаларыннан, 90 яшьтән өлкәнрәк өлкән гражданнардан һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пункт территориясен төзекләндерү;

“Әйе” “Каршы”

2. Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлегенең Өлә авылында үзара салым акчаларын көләну мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 14.11.2024 көненә билгеләргә. Үткәрү вакыты - 13 сәгать 00 минутта. Үткәрү урыны: Казаклар мәдәният йортында адресы: уля авылы, Совет ур., 11 йорт.

2.1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлегенең Казаклар авылы торак пункты территориясендә даими яшәүче, яшәү

урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы Сез, свода катнашучы халыктан һәм аларның бергә яшәүче гаилә әгъзаларыннан, 90 яшьтән өлкәнрәк өлкән гражданнардан һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү.

“Әйе” “Каршы”

3. Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлегенең Наратлык авылында үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 14.11.2024 көненә билгеләргә. Үткәрү вакыты - 16 сәгать 00 минутта. Үткәрү урыны: Ислейтар авыл клубында адресы: Наратлык авылы, аринская ур., 5нче йорт.

3.1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлегенең Наратлык авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы?:

- торак пункт территориясен төзекләндерү.

“Әйе” “Каршы”

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. http://vysokaya-gora.tatarstan.ru авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Сафин